| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НУРЛАТСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>НОРЛАТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ с.Нурлаты КАРАР

18 август 2023 ел №125

Норлат авыл җирлеге Советының 2021 елның 12 июлендәге 40 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (Норлат авыл җирлеге Советының 2022 елның 22 августындагы 77 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән).

«Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 № 498-ФЗ Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 №131-ФЗ, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Норлат авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Норлат авыл җирлеге Советының 2021 елның 12 июлендәге 40 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (Норлат авыл җирлеге Советының 2022 елның 22 августындагы 77 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Кагыйдәләрне түбәндәге эчтәлектәге 1 нче кушымта белән тулыландырырга:

Норлат авыл җирлеге Советының 2021 елның 12 июлендәге 40 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә 1 нче кушымта.

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар

исемлеге».

1. Балалар уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.

2. Җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, күпләп ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).

3.Мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.

4. Мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.

5. Җәмәгать туклануы оешмаларына, сәүдә объектларына, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннарына якын территорияләр.

6. Зират.».

2. Хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына хуҗасыз кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затларның түбәндәге исемлеген билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башлыгы;

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Норлат авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында: Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (поселение администрациясе бинасы), Норлат авылы, М.Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Волга аръягы»ЦКС бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

И.М.Саттаров